Муниципальное бюджетное учреждение культуры «Бардымская централизованная библиотечная система»

# БАРДА ЯГЫ СӨЙЛӘКЛӘРЕ, РИВАЯТЬЛӘРЕ ҺӘМ МИФЛАРЫ

## Были, легенды и мифы Бардымского района, рассказанные старожилами района.

С.Барда,2015

## Борчак басу

Элек, Амировка авылы булмаганда, Карманнан Күчтәнтигә турыдан “Мөәзин жире” аша йөргәннәр. Дымлы җир булганга бу җиргә борчак чәчкәннәр, бәрәңге утырткannaр.Ул җирнең мәйданы 13 гектардан күбрәк булган. Сафиулла Габдрашитов сөйләве буенча , бу җирдә борчакка бала-чага биссмилла әйтмичә керми торган булалар. Күчтәнтигә турыдан баручылар да таптамаска тырышып, басу кырыеннан гына йөргәннәр.

Безнең колхозда гражданнар сугышында Врангельгә каршы сугышта аягын өздергән, аксаклап йөрүче Шакиров Габдулла абый агроном булып эшләде. Ул аягы авыртса да, колхоз басуларындагы уңышны җәяүләп тикшереп чыга иде. “Мөәзин жирендә” борчак чәчкән булганга, уңыш бик яхшы була. Борчак кузаклары эре, тулы, тәмле булып җитешеп килә. Габдулла абый берничә баланың борчак ашап ятканын күреп, “барыбер минем яннан үтәләр”, - дип, борчак арасына чүгәләп утыра һәм йоклап китә. Күзе йомылып бетми, кырына ап-ак киемле, кәләпүш кигән бабай килеп баса да:

-Балаларга тимә, бу җир минем, ашасыннар, мин бу басуны улларым белән файда килсен өчен арчыдым, дип күздән югала. Габдулла абый куркып күзләрен ачуга, балалар да юкка чыккан, теге бабай да күренми. Менә нинди мәрхәмәтле, изге җанлы, кешелекле булган ул Хәбибрахман мөәзин!

2014 ел. “Изге төш” – Шакиров Габдулла турында( Габдрашитов Сафиулла Хөрмәт улы 82 яш), язып барды Валитова Фәнүзә Мөнир кызы.

## Гороховое поле

Раньше, когда еще не было Амировки, из Кармановки в Константиновку ходили через так наываемые “земли муэдзина”. Так как место было влажное, на поле выращивали горох и картофель. Площадь поля составляла более тринадцати гектаров. По словам Габдрашитова Сафиуллы, ребятишки не заходили на это поле без молитвы. Идущие напрямую до Константиновки также старались не топтать его, обходили по краю.

Агрономом в нашем колхозе работал Шакиров Габдулла абый, потерявший ногу , сражаясь против Врангеля во время гражданской войны. Несмотря на болевшую ногу, он пешком обходил колхозные поля, чтобы проверить урожайность. На “Поле муэдзина” был посеян горох, урожай очень хороший, стручки крупные, полные, набираются сладости и спелости.

Увидев несколько ребятишек, лакомившихся горохом, Габдулла абый прячется, рассудив, что они все равно пройдут мимо него, и неожиданно засыпает. Закрываются сонные глаза и перед ним появляется дед во всем белом и говорит:

-Детей не трогай, это моя земля, пусть едят. Я эту землю расчищал, чтобы она приносила пользу и исчезает. Габдулла абый пугается. Открывает глаза , а на поле ни детей, ни деда.

Вот каким сердобольным, человечным и добропорядочным был муэдзин Хабибрахман.

2014г. “Благой сон”- о Шакирове Габдулле (Габдрашитов Сафиулла Хурматович, 82 года) записала Валитова Фануза Мунировна, д.Кармановка.

**Ракы чишмәсе**

“Калтау ара” буенда Әрәкәй исемле кешенең җире булган. Суы булманга Калтау арасында кое казып карарга булган. Тирән дә казырга кирәк булмаган, су күренгән. Элек “җир көндек” булып чыккан, аннан суы күбәя барып чишмәгә әверелгән. Элек бу чишмәне “Әрәкәй чишмәсе” дип атап йөрткәннәр, ә хәзер “Ракы чишмәсе” дип атала.

2014 ел. Маматова Тәрҗимә Гафи кызы сүзләреннән китапханәче Юлаева Фәнисә Хәмис кызы язып алды. Түбән авыл.

**Водочный родник**

Вдоль Калтау находилась земля человека по имени Аракай. Так как там не было воды, он решил попробовать выкопать колодец. Выкопал совсем неглубоко, и появилась вода. Сначала она била небольшим ключиком, затем превратилась в родник. Вначале его называли родник Аракая, а сейчас зовут “Водочный родник”. По-видимому, из-за того,что имя хозяина родника по- татарски похоже на название алкоголя.

2014 г. Со слов Маматовой Тарзимы Гафиевны записала библиотекарь Юлаева Фаниса Хамисовна. Д.Ишимово.

**“Мегәтебәр күле”**

Мөгәтәбәр исемле бабай кабык төшереп, мунчала салып, чептә сугып көн күргән. Мунчала салган күлне “Мөгәтебәр күле” дип атап йөрткәннәр. Хәзерге вакытта “Мәгәтебәр күле” дип атап йөртелә.

2014 ел. Маматова Тәрҗимә Гафи кызы сүзләреннән китапханәче Юлаева Фәнисә Хәмис кызы язып алды. Түбән авыл.

**Озеро Магатебара**

Дед по имени Магатебар жил тем, что мочил лыко, готовил мочало и ткал рогожу. Озеро, на котором он этим занимался, называли озеро Магатебара. И сегодня это озеро называют “Озеро Магатебар”.

2014 г. Со слов Маматовой Тарзимы Гафиевны записала библиотекарь Юлаева Фаниса Хамисовна, д. Ишимово.

**“Майбәдәр күл эч”**

Мәгәтебәр күленнән аз гына китеп Майбәдәр исемле әби мунчала салып, чептә суккан. Мунчала салган күлне “Мәйбәдәр күле” дип атап йөрткәннәр. Хәзерге вакытта бу күл корыган, җирен “Майбәдәр күл эч” дип атап куйганнар. Мәгәтебәр һәм Майбәдәр күлләре Тол елгасына агып төшкәннәр.

2014 ел. Маматова Тәрҗимә Гафи кызы сүзләреннән китапханәче Юлаева Фәнисә Хәмис кызы язып алды. Түбән авыл.

## Местечко Майбадар

Бабушка Майбадар мочила лыко, делала мочало, чтобы затем плести рогожу. Было это недалеко от озера Магатебар. Озеро, где она трудилась, называли озером Майбадар. В настоящее время озеро уже высохло, а место , где оно находилось , называют местечком озера Майбадар. Озеро Магатебар и Майдабар впадали в Тулву.

2014 г. Со слов Маматовой Тарзимы Гафиевны записала библиотекарь Юлаева Фаниса Хамисовна, д. Ишимово.

## Карман авылы

Карман авылы Барда районының көньяк – көнчыгышында, Тол елгасының сул кушылдыгы Чәпчелде елгасы буенда табигатьнең иң гүзәл почмагында урнашкан. Авылыбызның исеме кара урман белән бәйле.

Карман – Чәпчелде һәм Карман елгалары арасына урнашкан. 1904 елда барлыкка килгән. Карман – караурман (дремучий лес) сүзеннән алынган.

Авылның килеп чыгышы турында халык телендә шундый риваять сакланып калган. Имеш, Габдрахман исемле Сараш кешесе йортын салып бетергәч, Сараш авылына гаиләсен алырга кайткан. Күршеләре кайсы авылга күченәсез дип сорауга: “Кара урманга” диясе урынга ул тотлыгып: “Карманга”, дип җавап биргән. Шулай итеп, Карман авылынының исеме “кара урман” сүзләреннән кыскартылып алынган булырга тиеш. Чөнки, авыл урынында йөзәр яшьлек чыршылар, төп – төз каеннар үскән, кара урман булган.

Өлкән яшьтәге Нурбаев Фазыл, Газихан бабайлар сөйләве буенча, алар икесе ике урамда яшәгәннәр. Бер урамннан икенче урамга барганда, адашмас өчен агачны юнып билге - тамга куя торган булганнар. Хәзерге көндә дә үткән елларга һәйкәл булып мәктәп бакчасында зур чыршы үсә. Чыршыга карасаң, баштан бүрек төшәрлек, ике кешенең дә кочагы җитмәслек.

Чыннан да авылга беренче нигез салучылар Сарашка, Печмень кебек авылларга барган чакта адашмас өчен йомычка ыргытып барулары турында да сөйли иде борынгы бабайлар, картәтиләр. Кешеләр, күчеп килүчеләр, шушы йөзәр яшьлек чыршыларны егып, урынында йортлар төзгәннәр, агачларны яндырып җирне арчыганнар. Елдан – ел чәчү җирләрен киңәйткәннәр. Һәр күчеп килүче үзенә җирне бик тырышып арчыган. Күп хезмәт түгеп яулап алган. Шайморат җире, Шәмсетдин җире, Барыйның шома җире, Габделкавыйның мәк тавы, Мәәзин җире, Гарафетдин җире кебек басу җирләр шушы җир хуҗаларының кем булуын аңлата.

Авыл ике инеш: Чәпчелде һәм Карман инешләре арасына урнашкан. Авылга килеп җитми торып, аны үзен күрмисең. Ни өчен дисәң? Авыл тау астына урнашкан. Тау башыннан караганда “А” хәрефенә ошап тора.

Карман авылы район үзәгеннән 45 км., Чернушка шәһәреннән 37 км. ераклыкта 3 район: Барда, Уен, Чернушка районнары кисешкән урында урнашкан.

Уен районына кергән Толбаш авылына турыдан 7 км, Чернушка районы Ермия авылына 9 км. ераклыкта.

2014 ел. Материалларны җыеп язып барды Валитова Фәнүзә Мөнир кызы.

## Кармановка

Кармановка находится на юго-востоке Бардымского района, расположена в красивейшем уголке природы, вдоль реки Чапчельда, левого притока реки Тулвы. Название села связано с дремучим (черным) лесом.

Карман – татарское слово. По историческим источникам, оно происходит от слова “черный лес”. Кармановка – деревня на реках Чапчелде и Кармановке основана в 1904 году.

В народе сохранилась такая легенда о происхождении деревни Кармановка. Будто бы , сарашевец Габдрахман, достроив дом, отправился в Сараши забирать семью. Когда соседи спросили: “В какую деревню переезжаете?” Заикаясь , ответил: “ Карманга”, вместо “Кара урманга”. Таким образом и появился сокращенный вариант слов “кара урман” – “карман”. В то время на месте Кармановки росли вековые ели, высокие прямые березы, был дремучий лес.

По рассказам Газихан бабая и Нурбаева Фазыла, они жили на разных улицах. Чтобы добраться с одной улицы до другой, не заблудившись, отмечали путь зарубками на деревьях. Сегодня памятником тем стародавним временам на школьном участке растет старая ель. Если посмотреть на ее вершину, упадет шапка, а ее ствол не помещается в два человеческих обхвата.

Действительно, древние старики и наши деды рассказывали, чтобы не заблудиться по дороге до Сарашей и Печмени, они отмечали свой путь щепой. Переселенцы валили столетние деревья, расчищая место для построек, сжигали лес, чтобы подготовить землю для хозяйствования. Ежегодно расширяли посевные площади. Каждый переселенец старательно готовил участки для посевов, с трудом завоевывал каждый кусочек земли. Земля Шаймората,Шамсетдина, равнина Барыя, Маковая гора Габделькавыя, Земля муэдзина, поле Гарафетдина... Эти названия говорят, кому принадлежали поля.

Село расположено между двумя реками Кармановкой и Чапчельдой. Его не видно до тех пор, пока не подъедешь. Почему? Кармановка располагается под горой. Когда смотришь на нее с высоты, она напоминает букву “А”.

Кармановка находится на расстоянии 45 километров от районного центра, в 37-ми километрах от Чернушки, располагается на пересечении трех районов – Бардымского, Уинского, Чернушинского. До деревни Тулбаш Уинского района напрямую 7 километров, до деревни Ермия Чернушинского – 9 километров.

2014 год. Материалы собрала и записала Валитова Фануза Мунировна.

## Мөәзин риваяте

Әтием колхоз председателе булып эшләгәндә иртә белән, без торганчы, басуларны, игеннәрнең ничек тишелеп чыкканын карарга чыгып китә торган иде, кайчакта аның

белән бергә ревизия  комиссия председателе Нурбаков Шыргазыйхан бабай да чыга торган иде.Бервакыт аларның бергә чәй эчеп,  (иртәнге чәй) сөйләшеп утырганда әтинең Шыргазыйхан бабайга:

- Ап-ак күлмәк, ыштанын киеп игеннәрне таптамас өчен, урман кырыеннан мөәзин абыйның килгәнен күрдеңме? Һәр елны игеннәрне күзәтеп тора. Быел күренерме, дип уйлап кына беттем, агачлар арасыннан килеп тә чыкты.

- Ничек күрмисең, миннән ерак түгел иде... - дип сөйләгәнен ишеттем дә, этиләр правлениегә төшкәч, әнидән сораган идем, әни миңа болай дип җавап бирде:

- Мөәзин бабай күптән үлде инде. Ул галим кебек күпне белә торган мулла булган. Ул басуны уллары белән арчыган, агачыннан йорт – абзар, мунча төзегән, җирен арчып, басу ясаган. Колхоз төзелгәч, җирен үзе теләп, колхозга биргән. Ул җир хәзер дә Мөәзин җире дип атала.

-Әни, үлгән кешеләр йөримени? – дип сорагач.

-Изге, яхшы кешеләрнең рухлары йөри ул! – дип җавап бирде.

2014 ел. Материаларны  җыеп, язып барды Валитова Фәнүзә Мөнир кызы, Карман авылы.

## Легенда  муэдзине

Когда мой отец работал председателем колхоза, с утра, пока мы еще не проснулись, он отплавлялся на колхозные поля, чтобы проверить всходы... Иногда с ним вместе выходил и Нурбаков Шыргазихан бабай. Как то раз , когда они вместе пили утренний чай, отец спросил у Шыргазихан бабая:

-Ты видел муэдзин абыя, одетого в белые одежды , идущего по краю поля, чтобы не топтать посевы?  Каждый год обходит поле. Только подумал, увижу ли его и нынче, как он и появился из-за деревьев...

- Как же не видел, он же был недалеко от меня!?

Услышав такое, после того как отец с Шыргазихан бабаем отправились в правление,  я  стала распрашивать маму. Мама мне ответила:

-  Муэдзин бабай давно умер. Он был очень образованный мулла.  Это он расчищал поле вместе с сыновьями, а деревья использовал для строительства дома , бани и овина. Когда образовался колхоз, добровольно отдал землю. До сих пор это поле называется полем муэдзина.

- Мама, разве мертвые ходят,- спросила я.

- Душа хороших и святых людей ходит, - ответила она мне.

2014 год. Собрала и записала материал Валитова Фануза Мунировна, д.Кармановка.

## Мостовая

Борынгы заманда Оса районның Мостовая авылында безнең ата-бабаларыбыз яшәгәннәр. Руслар килеп татарлардан:  “Үгез тиресе киңлегендә җир бирең әле безгә”,- дип сораганнар. Ә татарлар риза булганнар: үгез тиресе зур түгел, күп җир сораймылар, дип уйлаганнар. Ә руслар хәйләкәр булганнар. Руслар үгез тирене җеп кебек нәзек кенә итеп кискәннәр һәм татарлар урнашкан җирләрне чолгап алганнар. Монысы безнең җир инде, сезнең җирегез юк, диеп татарларны  куганнар. Рус Мостоваяда яшәгән татар халкы Барда якларына (Каҗмактыга) күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Сүҗде авылы шуннан соң барлыкка килгән.

2014 ел. Гафурҗан Хәсәнҗан улы Акбашев сөйләгән сүзләрне Сүҗде авыл китапханәчесе Юрушбаева Дәмирә Исмагыйл кызы язып алды.

## Мостовая

В давние времена в деревне Мостовая Осинского района жили наши прадеды. Русские пришли и попросили: “Дайте нам немного земли, всего с бычью шкуру”. Татары согласились, поразмыслив, что они просят совсем немного земли. Только с бычью шкуру. А русские оказались хитрыми: они разрезали бычью шкуру на тончайшие нити и окружили этой нитью татарское селение . “Это уже наша земля, вашей земли нет,”- заявили они и прогнали татар. Татары, проживающие в русской Мостовой, вынуждены били переселиться в бардымские края, к Казьмакты. После этого и образовалась деревня Мостовая в Бардымском районе.

2014 год. Со слов Гафурзяна Хасанжановича Акбашева записала библиотекарь Мостовинской библиотеки Дамира Исмагиловна Юрушбаева. Д.Мостовая.

## Карабай чишмәсе

Ахун исемле бабай урманда, куларада, артык кояш нурлары төшмәгән җирдә, чишмә казган. Карангырак урын булганга Карабай чишмәсе дип атаган.

2014 ел. Гафурҗан Хәсәнҗан улы Акбашев сөйләгән сүзләрне Сүҗде авыл китапханәчесе Юрушбаева Дәмирә Исмагыйл кызы язып алды.

## Черный родник

В лесной лощине, куда плохо проникают солнечные лучи , Ахун бабай выкопал родник. Так как место это было темное , назвали родник Карабай (Черный).

2014 год. Со слов Гафурзяна Хасанжановича Акбашева записала библиотекарь Мостовинской библиотеки Дамира исмагиловна Юрушбаева. Д.Мостовая

## Шакиров буамнары

Бөек Ватан сугышы елларыннан соң Шакиров өчне буам каздырган. Беренче буам асфальт күперенең өске ягы, сул һәм уң якларында. Бу буамнарга Суксун районыннан балыклар барып алып буамнарда үрчеткәннәр. Халык аларны Шакиров буамнары дип атаган.

2014 ел. Гафурҗан Хәсәнҗан улы Акбашев сөйләгән сүзләрне Сүҗде авыл китапханәчесе Юрушбаева Дәмирә Исмагыйл кызы язып алды.

## Запруды Шакирова

После окончания Великой Отечественной войны Шакиров соорудил три запруды. Первая запруда вверху возле моста у асфальта, вторая и третья слева и справа моста. Для

запруд из Суксуна привезли мальков и разводили рыбу. Народ назвал эти запруды Шакировскими.

2014 год. Со слов Гафурзяна Хасанжановича Акбашева записала библиотекарь Мостовинской библиотеки Дамира Исмагиловна Юрушбаева.Д.Мостовая

**Аракы чишмәсе**

Бу чишмәнең суы бик чиста, корымый торган. Хәзерге көнгә кадәр халык суын эчә. Суы чиста булганга шулай атаганнар.

2014 ел. Гафурҗан Хәсәнҗан улы Акбашев сөйләген сүзләрне Сүҗде авыл китапхәнәчесе Юрушбаева Дәмирә Исмагыйл кызы язып алды.

**Водочный родник**

Вода в этом роднике очень чистая, не высыхает. И  посей день народ пьет воду из этого родника. А назвали его водочным потому, что в нем очень чистая, прозрачная вода.

2014 год. Со слов Гафурзяна Хасанжановича Акбашева записала библиотекарь Мостовинской библиотеки Дамира Исмагиловна Юрушбаева.Д.Мостовая

**Ибрай чишмәсе**

Элек заманда Ибрай исемле мулла абзый үз хуҗалыгында күп итеп маллар караган. Ә иген икенче җирдә чәчкән. Ул игенен сакларга бара торган булган. Бервакыт мулла абзый урман буйлап барганда дошманнар килеп чыгып аңа атканнар. Үле гәудәсен чишмә янында тапканнар. Шуннан соң халык чишмәне Ибрай чишмәсе дип атаган.

2014 ел. Гафурҗан Хәсәнҗан улы Акбашев сөйләген сүзләрне Сүҗде авыл китапхәнәчесе Юрушбаева Дәмирә Исмагыйл кызы язып алды.

**Родник Ибрая**

В давние времена жил мулла по имени Ибрай, в своем хозяйстве он содержал очень много живности, а хлеб выращивал в другом месте.  Обычно он отправлялся охранять свои хлеба. Как-то раз, когда  шел вдоль леса, на него напали разбойники и застрелили. Его труп нашли возле родника. После этого родник и  стали называть родником Ибрая.

2014 год. Со слов Гафурзяна Хасанжановича Акбашева записала библиотекарь Мостовинской библиотеки Дамира Исмагиловна Юрушбаева.Д.Мостовая

**Сөт чишмәсе**

Чишмәнең суы аксыл сөт төсле булганга шулай атаганнар.

2014 ел. Гафурҗан Хәсәнҗан улы Акбашев сөйләгән сүзләрне Сүҗде авыл китапхәнәчесе Юрушбаева Дәмирә Исмагыйл кызы язып алды.

**Молочный родник**

Так назвали родник потому, что его вода мутная, напоминает молоко.

2014 год. Со слов Гафурзяна Хасанжановича Акбашева записала библиотекарь Мостовинской библиотеки Дамира Исмагиловна Юрушбаева. Д.Мостовая

**Нуриш басуы**

Безнең туган илебез Русия-Рәсәй дип атала, ә без туган җир – Пермь өлкәсе иде элек, ә хәзер Пермь крае, Барда районы, Карман авылы. Туган авылыбыз крайның көньягында: 3 район - Уен, Барда, Чернушка районнары кисешкән урында бер кечкенә нокта гына булып күренсә дә, безнең өчен иң зур иң кадерле җир булып тоела.

Туган җир... Туган авыл... Карманым... Йөрәккә бик кадерле бу сүзләр. Бүгенге кечкенә язмада бераз авылым тарихы, топонимикасы, кайбер таулар, басулар турында авылда туган легенда, мифлар белән таныштырып китәрбез.

Авылым исеме дә "кара урман" сүзеннән алынган. 1904нче елда җир эзләп килүче ата-бабаларыбыз (Сараш авылыннан) Күчтәнтидән соң кара урман аша килгән чакта, адашмас өчен, йомычка орып , агачларга билге куеп , тау астына төшеп, 2 чишмә - хәзер ул инешләр –Карман һәм Чәпчелде дип аталган җиргә килеп урнашканнар. Килеп җитү белән зур-зур чыршыларны егып басулар , чәчүлек җирләре ясый башлаганнар, өйләр дә төзегәннәр.

Авылым тау астында, Урал тавы итәгендә урнашканга, урман арасыннан килгәндә таудан төшеп җитми торып, авылны күрмисең. Таулар авылны көчле өермәләрдән, бураннардан саклый. Алар барысы да Чал Уралның дәвамы.

Һәр авылның үз язмышы, үз тарихы бар. Авылның төп кәсебе игенчелек булгач, күчеп килүчеләр кара урманнар, тау итәкләрен арчып чәчүлек җирләре – басулар арчып иген чәчкәннәр. Һәр тауга, һәр арчыган басуга исем – атама биргәннәр : "Мәэзин җире", "Мифтах", "Мөхәммәт тау буе", "Эшләпәле тау"... Таулар дигәч, безнең авыл гел таулар белән чолганган, аларның исемнәре дә төрле- төрле: "Зыярәт", "Хәйдәр тау", "Усак тау", "Андрей тау", "Габделхәй тау"; басулар да шушы тау итәкләрендә урнашкан. Мин сөйлиячәк легенда бер исемсез басу турында булачак. Бу басу Барда районы чигендә Чернушка районы белән чикләшкән. Андрей тау итәгендә урнашкан (ул "Капкан", "Кандала" авылларына 2-3 км. кала, "Андрей тау" Чернушка районныда иң биек , текә тау). Элек бу тау астында качкыннар, юл басучылар яшеренеп ятканнар. Пугачев Е. гаскәрләре Оса шәһәрен яулый алмагач, чигенеп килгәндә патша гаскәрләре тарафыннан Капкан авылы янында чолганышта калып Кандала авылына чигенәләр. Күп кенә башкүтәрүчеләр качып Андрей тау итәгендә яшәгәннәр. Соңга таба восстаниячәләр бөтенләй тар-мар ителгәч Ристанка авылына нигез салып, авыл төзегәннәр (хәзер Максимовка) дип атала. Моның турында безгә Кандала авылының өлкән кешеләре экскурсиягә барганда сөйләгәннәр иде, ә мәктәптә тарих укытучы Мунасипов Мулләхмәт абый мавыктыргыч итеп сөйли торган иде.

Мин сезгә сөйлиячәк легенданы, әйтеп үткәнемчә шушындагы Карманның бер иң соңгы басуы турында язырга уйладым. Бу легенданы авылда төрле кеше төрлечә сөйли, ләкин төп герой чын, ул авыл кешесе, аның авылда туганнары яши.

Карман авылына нигез салу белән, Ибраевлар нәселе күп балалы гаиләсе белән килеп урнаша, һәм башта Усак тау итәгендә, аннан соң Андрей тау итәгендә арчып, агачларын яндырып, берсеннән-берсе таза малайлары белән басу эшкәртеп, борчак

чәчәләр. Әле ул вакытта колхозлар оешмаган , һәр кем үз җирен эшкәртә, ура, суга, артыгын, уңышны җыеп алгач, сата. Комбайн, трактор турында сүз дә юк. Карманда күп кеше уртакка эшли, икенче төрле әйткәндә, эшләгән өчен уңышның бер өлешен үзенә алып кала.

Ибраев Гаплаҗан абыйның күршесендә кечкенә генә йортта бик тырыш , сөйкемле ике баласы белән Нурикамал исемле хатын яши. Аның ире Беренче Бөтендөнья сугышына китеп, хәбәрсез югала. Бу тырыш хатын кешеләргә алмашка, уртакка эшләп көн күрә. Авылда эш беткәч, күрше авыллар : Коробейник, Калиновка, Капканга иптәшләре белән барып, кыш чыгарлык азык-төлек эшләп көн күрә. Ике баласы да кул астына керә башлый. Авыл халкы тырыш хатынны үз итә: сөтен, маен, итен бирәләр. Гел эшкә дәшәләр. Сабан туйларында теттереп биюе генә дә үзе ни тора! Кышын эрли, суга, җилгәрә...

Аны халык яратып Нуриш дип атый. Гаплаҗан бабай Нуриш белән сөйләшеп борчак өлгергәнне, аны йолкырга вакыт икәнлеген әйтеп, Нуришне борчак йолкырга чакыра, эшенә карап борчак, арыш, бер сарык вәгъдә итә.

- Яңгырларга кадәр сугып, келәтләргә кертеп калсак, бик яхшы булыр иде, ди.

Өч көн Нурикамал балалары белән барып эшләп, бер көнлек кенә эш калгач, сөенә-сөенә балалары белән әкрен кайтырга чыгалар, ләкин кечкенә 5 яшьлек малай, әллә күп борчак ашаганга, әллә көн буе кояшта утырып арыганга, шыңшый, атлыйсы килми. Ярый ярты юлны үткәч, ә бу ара аз түгел – 3-4 чакырым булыр, Нурикамал балаларны Гәрәй абзый атына утыртып кайтарып җибәрә.

-Иртәгә күп калмады, балалар, үзем генә барып бетереп куярмын ди.

Ә иртә белән балаларны ашатып-эчертеп, үзе генә, кояш чыгу белән басуга кузгала. Шуннан соң аны тере килеш бер кем дә күрми. Кич җитә, балар юлга чыгып әниләрен көтәләр, ләкин ул күренми. Балалар үзләре генә йоклыйлар. Иртә белән Гаплаҗан бабайның хатыны кереп хәлне белешә. Кайтмаганын белгәч, Гаплаҗан бабай Гарифҗан исемле улы белән атка утырып эзләргә - басуга китәләр. Басуга баргач озак эзлиләр һәм басу кырында аркасына урак кадалган килеш, борчак өемнәре арасында табып алгач, аптырап калалар, аның янында бик күп борчак белән капчык тора, борчак өемнәре тузгынган, чабатасы төшеп калган...

Гаплаҗан бабай:

-Кемдер борчакны алып кайтырга әзерләгән, Нуриш мәрхүм белән бик тартышканнар. Мескенем, шушы борчакны саклап һәлак булган. Теге урман разбойниклар эшедер, менә итек эзләре, тәмәкесе аунап ята. Әйдәгез, арбага салыйк, алып кайтыйк, исләнә башлаган, эссе бит. Кара, күпме кан югалткан !- ди

Авыл халкы бик зурлап Нуришне –Нурикамалны соңгы юлга озаталар... Ә балаларын Гаплаҗан бабай тәрбияләп үстерә, кеше итә. Нуриш кызы Рәйсә апаны мин дә беләм азырак. Кеше гел сөйли торган иде.

Ә теге басуны, хәзер дә Нуриш басуы диләр. Колхоз ул басудан зур уңыш ала торган иде. Шунысын әйтеп китәсе килә, комбайнер Субхангулов Галимҗан абый белән Хабибҗан Ижбулатов шул басуны эшкәрткән вакытта бер гаҗәп хәлгә очрыйлар: Нуриш үлгән урында ук кан шикелле кып-кызыл шөхтил (марьин корень) чәчәкләр үскәнен күреп гаҗәпкә калалар. Ул чәчәкләр куак сыман булып чәчәк атканнар.Ә уңыш җыйганда шул чәчәкләр вак бөртекләр чыгарып, без муенса- мынчак ясый идек. Бу чәчәкләр исе тәмсез, өйдә утыртып булмый, тамырлары бик файдалы. Хәзер ул төрле җирләрдә үсә , Усак тау ягында. Иртә чәчәк атканга без, пионерлар, элек Пионерия көненә Бардага сулы чиләккә утыртып алып бара идек. Башка авыл балалары каян алдыгыз дип гаҗәпкә кала иделәр. Ул Кызыл китапка кертелгән, Урал тау итәгендә һәм бездә үсә. Без “Нуриш чәчәгә” дибез. Яхшы кеше үзе үлсә дә исеме кала.. эзе кала: “Нуриш басуы, Нуриш чәчәге, Нуриш тавы”.

...Шохтил чәчәк кызыл кан шикелле,
Нуриш каннан үсеп чыкканга.
Чәчәкләре матур, исе тәмсез
Озак итеп җирдә ятканга.

Нурикамал тырыш ана булган.
Тормыш алып барган бер үзе.
Ике баласы да аны бик яраткан,
Тыңлаган әни сүзен.

Борчак чапкан, бик ашыккан
Вакыт үткәнен сизми.
Явыз качкын күзәткәне
Аның уена килми.

Урак белән каршы тора,
Пычак тоткан ир-атка.
Көчле ирне җинеп булмый.
Пычагын кадый артка.

Нурикамал егыла да,
Урагы төшә кулыннан.
Кем соң аны алып кайтыр
Кызы белән улына?

Соңгы сүзе "Аллакаем!
Ике сабыем кала!"
Пычак кадаган урыннан,
Кып-кызыл каны ага.

Бер елдан соң бу урында
Шохтил чәчәге атты.
Кызыл чәчәкләрне күргәч,
Авылдашлар шак катты...

Нуриш басуына килеп,
Шохтил чәчәк өзмәгез!
Явыз бурдан һәләк булган
Нуришне онытмагыз!

Укытучы-ветеран Вәлитова Фәнуза, Карман авылы, 2014 ел.

## Поле Нуриш

*Родная земля... Родное село... Кармановка. Дорогие сердцу понятия. Сегодняшнее небольшое повествование посвящаю истории села, топонимике гор, пашен , записаным легендам и мифам.*

Название села происходит от татарского слова “черный, темный, дремучий лес”. Наши предки в 1904 году в поисках свободных земель пробирались по дремучему лесу, который начинался возле Сарашей и Констинтиновки и, чтобы не заблудиться, делали зарубки на деревьях, бросали на дорогу щепу. Остановились под горой в междуречье Чапчельды и Кармановки. Свалив огромные ели, расчистили место для пашен и лугов, начали строить дома.

Село располагается у подножья Уральских гор, пока едешь по лесу, не спустившись с горы, села не заметишь. Горы, которые являются продолжением Седого Урала, защищают деревню о сильных смерчей и буранов.

У каждого села есть своя судьба и своя история. Основная деятельность сельчан земледелие, поэтому первопосенленцы вырубали дремучий лес и очищали склоны гор под поля, засевали их зерновыми культурами. Каждой горе, каждому полю дали название – “Земля муэдзина”, “Мифтах”, “Предгорье Мухаммата”, “Гора в шляпе”... Наше село со всех сторон окружено горами, все они имеют различные “имена” – “Кладбищенская”, “Гора Хайдара”, “Осиновая гора”, “Андреева гора”, “Гора Габдулхая” и поля расположены в их предгорьях или на горах.

Легенду, которую я хочу пересказать , нельзя назвать легендой, это похожее на миф повествование об одном безымянном поле. Это поле на краю района , граничит с Чернушинским районом и располагается в предгорье Андреевой горы, до деревень Капкан и Кандала оттуда 2-3 километра. Андреева гора самая высокая и крутая в Чернушинском районе. Раньше возле этой горы прятались разбойники и беглые. Когда пугачевцы не смогли взять город Осу, они отступили, преследуемые царскими войсками, были окружены возле деревни Капкан, и отошли до деревани Кандала. Многие восставшие тогда сбежали и прятались возле Андреевой горы. Позже, когда восстание было полностью подавлено, они основали деревню Ристанка , сейчас она называется Максимовка. (*Об этом нам рассказали старейшины деревни, когда мы школьниками ездили на экскурсию в деревню Кандала, а в школе нам об этом рассказывал наш учитель истории Муксинов Муллахмат абый*)

Я хочу рассказать легенду о самом дальнем поле Кармановки. Эту легенду излагают в деревне по-разному, разные люди предлагают свои варианты, но главный герой – подлиный , это уроженка села, там живут ее родственники.

После основания деревни в Кармановку переселяется многодетная семья Ибраевых. Глава семьи вместе с сыновьями, один другого здоровее, вначале очищают от леса предгорье Осиновой горы, затем Андреевой горы, распахивают пашню и засевают горохом. Тогда еще не было колхозов и каждый сам обрабатывал и засевал землю, сам жал и молотил, а излишки продавал. О комбайнах и тракторах не было и речи. Многие в Кармановке работали исполу, то есть за работу получали часть убранного урожая.

По соседству с Ибраевым Гаплазяном в небольшом домике жила очень трудолюбивая симпатичная женщина по имени Нурикамал с двумя маленькими детьми. Ее муж ушел на Первую Мировую войну и уже три года как пропал без вести. Старательная женщина жила тем, что работала исполу или на паях. Когда в деревне работа заканчивалась, вместе с односельчанами отправлялась в соседние деревни Коробейник, Калиновка, Капкан и зарабатывала продукты ,чтобы пережить зиму, тем и перебивалась. И двое детишек начали по-немному помогать матери. Селяне полюбили старательную женщину, не обижали её, платили за работу молоком, маслом, мясом. Постоянно приглашали на работу. А чего стоили её задорные пляски на сабантуях?! Зимой она тоже не сидела без работы пряла, ткала, веяла...

Люди ласково называли ее “Нуриш”.

Гаплазян бабай как-то сказал Нуриш, что поспел горох, его нужно сжать, а после окончания работы побещал заплатить горохом, рожью и дать барана.

-Было бы неплохо, если бы до дождей сжать горох и поместить в клети, - прикинул он .

Три дня трудилась Нурикамал и с чувством удовлетворения вместе с детьми возвращалась с поля, рассчитывая, что работы осталось всего на  день. Но младший пятилетний мальчик начал капризничать, то ли от усталости, то ли объелся горохом. Хорошо еще, что на полдороге, а это 3-4 километра , детишек Нурикамал посадил на свою подводу Гарай абзый.

Вечером Нурикамал сказала детям: “Работы осталось немного, я схожу одна и закончу”. А поутру , накормив детей, с восходом солнца одна отправилась в поле. После этого никто ее не видел. Настал вечер, дети вышли на дорогу и ждали мать, ее не было видно, переночевали одни. На следующий день к ним в дом зашла жена  Гаплазян бабая, чтобы узнать, как дела. Узнав, что Нурикамал не возвращалась, Гаплазян бабай вместе со старшим сыном Гарифзяном, сев на подводу, отправились в поле искать Нурикамал. Добравшись до поля, долго искали и нашли лежащей на краю поля среди ворохов гороха с серпом, вонзенным в спину. Рядом  много мешков с горохом, кучи гороха разбросаны, лапоть спал с ноги.

Гаплазян бабай сказал:

- Кто-то приготовил горох, чтобы увезти, долго боролись с Нуриш, бедненькая, умерла, защищая чужое добро. Это ,  наверное, дело лесных разбойников, вон след сапога, сигарета... Давайте положим  ее на телегу. Надо везти, на улице жарко. Смотри, сколько потеряла крови !

Сельчане с почестями проводили Нуриш – Нурикамал в последний путь. А детей взял на воспитание и вырастил Гаплазян бабай.  И я  немного по рассказам сельчан знаю дочку Нуриш Раису.

А то поле и сейчас называют полем Нуриш. Колхоз на этом поле получал большие урожаи. Хочется рассказать интересную историю. Во время обработки этого поля комбайнер Галимзян Субхангулов и Хабибзян Ижбулатов  столкнулись с интересным явлением: на месте, где погибла Нуриш, они увидели кроваво-красные цветы (марьин корень), они росли как кустарник. А во время уборки урожая цветы превратились в маленькие бусинки, мы в детстве делали из них бусы. Запах у этих цветов неприятный, дома их ставить нельзя, зато корневища лекарственные. Сейчас пионы растут в различных местах возле Осиновой горы.  Пионы зацветают рано, и в День пионерии мы привозили их в Барду в ведрах с водой. Дети из других деревень удивлялись и спрашивали: “Где вы их взяли?” Этот цветок занесен в Красную книгу, растет в предгорьях Урала и у нас. Мы называем его цветком “Нуриш”. Когда умирает хороший человек, о нем всегда остается память : “Поле Нуриш, цветок Нуриш, гора Нуриш”.

Записала учитель- ветеран Валитова Фануза. Деревня Кармановка. 2014 год

| | |
|---|---|
| ...Шохтил чәчәк кызыл кан шикелле,<br>Нуриш каннан үсеп чыкканга.<br>Чәчәкләре матур, исе тәмсез<br>Озак итеп җирдә ятканга.<br><br>Нурикамал тырыш ана булган.<br>Тормыш алып барган бер үзе.<br>Ике баласы да аны бик яраткан,<br>Тыңлаган ани сүзен. | ...Пион красный, как кровь цветок,<br>Потому что вырос из крови Нуриш.<br>Цветы прекрасны, а запах неприятный,<br>Потому что долго лежала непогребенной.<br><br>Нурикамал была прекрасной матерью.<br>Одна тянула на себе жизненный воз.<br>Двое детей ее очень любили<br>Слушали каждое ее слово. |

| | |
|---|---|
| Борчак чапкан, бик ашыккан<br>Вакыт үткәнен сизми.<br>Явыз качкын күзәткәне<br>Аның уена килми.<br><br>Урак белән каршы тора,<br>Пычак тоткан ир-атка.<br>Көчле ирне җинеп булмый.<br>Пычагын кадый артка.<br><br>Нурикамал егыла да,<br>Урагы төшә кулыннан.<br>Кем соң аны алып кайтыр<br>Кызы белән улына?<br><br>Соңгы сүзе “Аллакаем!<br>Ике сабыем кала!”<br>Пычак кадаган урыннан,<br>Кып-кызыл каны ага.<br><br>Бер елдан сөң бу урында<br>Шохтил чәчәге атты.<br>Кызыл чәчәкләрне күргәч,<br>Авылдашлар шак катты...<br><br>Нуриш басуына килеп,<br>Шохтил чәчәк өзмәгез!<br>Явыз бурдан һәләк булган<br>Нуришне онытмагыз! | Жала горох, очень спешила<br>Незаметно пролетало время.<br>Не заметила злых воров,<br>Которые за нею следили.<br><br>С серпом стояла она<br>Против мужчин с ножами.<br>Не смогла одолеть женщина нападавших.<br>Вонзили они ей нож в спину.<br><br>Упала Нурикамал,<br>Выпал серп из рук.<br>Кто же привезет ее<br>К дочке и сыну?<br><br>Последние ее слова: “Аллах!<br>Остаются у меня двое детишек...”<br>Из раны стекает на землю<br>Красная кровь.<br><br>Через год на этом месте<br>Расцвели  красные пионы.<br>Увидев эти цветы,<br>Односельчане оторопели.<br><br>Придя на поле Нуриш,<br>Не рвите пионы!<br>Не забывайте Нуриш,<br>Погибшуют от рук злого вора! |

Учитель- ветеран Валитова Фануза. Деревня Кармановка. 2014 год.

**«Паранина яма»**

Недалеко от села Печмень находится место, которое называют «Паранина яма». Давным - давно это было, время было голодное. Параня пошла в лес за ягодами или грибами и меж двух логов упала в глубокую яму. Сил вылезти у нее не было, и она в этой яме умерла. С тех пор это место называют «Паранина яма».

2014 года. Со слов Рожковой Алевтины Алексеевны записала библиотекарь Рожкова Гузалия. С.Печмень

**«Семселяк»**

В Печменском поселении есть место, которое называется «Семселяк». Сюда когда-то пришли семь семей и основали деревню, которая впоследствии начала расти.

2014 год. Со слов Рожковой Алевтины Алексеевны записала библиотекарь Рожкова Гузалия. С.Печмень.

## «Каратаевка»

Название произошло от фамилии «Каратаев». Каратаев был богатый коммунар, который основал деревню. У него была мельница, и на него работало много народу.

2014 год. Со слов Рожковой Алевтины Алексеевны записала библиотекарь Рожкова Гузалия. С. Печмень.

## «Седловая гора»

В деревне Асюл есть гора в форме седла, поэтому она и называется «Седловая гора».

2014 год. Со слов Рожковой Алевтины Алексеевны записала библиотекарь Рожкова Гузалия. С. Печмень.

## «Березовый ключ»

В центре березовой рощи из-под земли бил ключ, поэтому и деревню назвали «Березовый ключ».

2014 год. Со слов Рожковой Алевтины Алексеевны записала библиотекарь Рожкова Гузалия. С.Печмень.

## Тауавыл

Тауавыл булгач, бездә таулар бик күп, барысының да исемнәре  бар. Маяк тау – исеменнән күренгәнчә, иң биеге, Тол тау – Тол елгасы буенда, монда Сабантуе үткәрелә, бу таудан Чувашай, Каенавыл, Байавыл, Үдик авыллары күренә. Шартлама тау – чыннан да җир җиләге күп була, Чишмә тау – “Бәләкәй чишмәсе” агып тора , Зыярат тау – олы юл белән икегә бүленгән, ике якта да кабер. Әубәкәр тау (бабайның исеме), 1,5 км га сузылган, Карагай тау, бу тауда аклар белән кызыллар сугышкан (Ә. Фатыйхов “Гэйнә иле” китабында 1919 елның җәендә 28нче Азин дивизиясе Акбаш, Уймуж, Үдикне, Әрәмавылны азат итә һәм Тол буена килеп туктала дип яза). Тауда турыпочмак фермасында чокырлар хәзер дә бар, окоплар булырга тиеш. Тагын Чилкәвеч дигән тау бар, исемсезләре дә бар тауларның авылыбызда.

2014 ел. Барсаев Махаматҗан Әхмәт улы сөйләвеннән Тауавыл китапханәчесе Барсаева Сәлимә язып алды.

## Усть-Тунтор

По- татарски наша дереявня называется Тауавыл – гористая деревня или деревня гора. У нас гор очень много, у каждой есть свое название, гора Маяк – самая высокая, гора Тул – находится возле реки Тулвы, здесь проводятся сабантуи. С горы можно увидеть деревни Чувашаево, Березники, Куземьярово, Елпачиху. Гора Шартлама, на ней действительно бывает много клубники. Чишма тау- там вытекает маленький родник, Зыярат тау- разделена дорогой на две части , по обеим сторонам кладбище, Аубакар тау –

названа по имени деда. На полтора километра тянется Карагай тау, на этой горе сражались белые и красные во время гражданской войны, возле фермы до сих пор сохранились ямы, по-видимому, бывшие окопы. Есть также гора Чилкявич, есть и безымянные горы.

2014 год. Со слов Барсаева Махаматзяна Ахматовича записала библиотекарь Усть-Тунторской библиотеки Барсаева Салима. Д. Усть-Тунтор.

**Хәбибрахман мөәзин бәете - Баит о муэдзине Хабибрахмане**

| | |
|---|---|
| Авылдашлар тыңлагызчы,<br>Бер сүз әйтү ниятем.<br>Мин җырлыймын, сез тыңлагыз<br>Хәбибрахман бәетен.<br><br>Тарих меңдә тугыз йөздә<br>Унынчы санәдә,<br>Башап Түздән безгә килде<br>4 балалы гаилә дә.<br><br>Хәбибрахман мөәзин булды,<br>Зәкиясе – абыстай.<br>Үзе тырыш, үзе матур,<br>Ә йөзләре - тулган ай!<br><br>Башап Түздән күчеп килеп,<br>Карурманга урнашты.<br>Мөәзин булса, иман булыр,<br>Диеп халык дуслашты.<br><br>Кулларына балта тотып,<br>Мәчет төзи башлады.<br>Икенче ел - Корбан бәйрәм,<br>Азан белән башланды.<br><br>Зәкия апа сабак бирде,<br>Карманның кызларына. | Односельчане, послушайте,<br>Хочу вам рассказать.<br>Я буду петь, а вы слушайте<br>Баит о Хабибрахмане.<br><br>В 1904 году<br>На десятый месяц.<br>Из Усть-Ашапа приехала к нам семья<br>С четырьмя детьми.<br><br>Хабибрахман стал муэдзином<br>Закия – его супруга-помощница.<br>Сама старательная, сама красивая,<br>А лицо , как полная луна.<br><br>Переехав из Усть Ашапа,<br>Поселились в дремучем лесу.<br>Если есть муэдзин, будет и вера<br>Решил народ и подружился с ним.<br><br>Взяв в руки топор,<br>Хабибрахман начал строить мечеть.<br>На следующий год праздник Курбан<br>Начался с азана.<br><br>Закия апа учила<br>Кармановских девушек. |

| | |
|---|---|
| 4 малае балык тотты,<br>Карманның суларында. | Четверо сыновей ловили рыбу<br>В реках Кармановки. |
| Усак тауның сул ягында<br>Мөәзин җирләр арчыды.<br>Хәбибрахманны онытмыйбыз<br>Шушы басу аркылы. | С левой стороны Осиновой горы<br>Муэдзин расчистил землю<br>Не забудем Хабибрахмана<br>Благодаря этому полю. |
| Фасиха һәм Мөнирә<br>Карманда туып үсте.<br>Икесе дә укытучы<br>Чаллыга күчеп китте. | Фасиха и Мунира<br>Родились и выросли в Кармановке.<br>Обе учительницы.<br>Переехали в Набережные Челны |
| Гомерләр бик тиз үтә ул,<br>Белегез кадерләрен.<br>Зияратта иң нурлысы,<br>Раскулов каберләре. | Жизнь летит быстро<br>Цените ее.<br>На кладбище<br>Самые светлые могилы - Раскуловых. |
| Яхина Гөлзифа Шәмсетдин кызы - “Мөәзин бәете”.<br>Күчтәнти авылы, 1992 ел. | Яхина Гульзифа Шамсеидиновна – Баит о муэтзине.<br>Д.Константиновка.1992 год. |

2014 год.Собрала и записала материал Валитова Фануза Мунировна. Д.Кармановка.

## Школьное привидение

Шермейская школа была построена на месте старого овина. В 1912 году здание было одноэтажное, каменное, в 1937 году к нему был пристроен второй, деревянный этаж.

Никто точно не помнит, когда это произошло, но охранники стали слышать, а иногда и видеть девушку в белом одеянии, которая чаще всего выходила из столовой (бывшее здание интерната) и бродила по коридорам. А иногда она стонала, как будто ей тяжело.

Говорят, что когда-то здесь была убита или школьница, или молодая учительница, и тело ее не было предано земле. С тех пор ее душа никак не может упокоиться.

2014 год. Записано со слов Волковой Ольги Модестовны, библиотекаря Шермейской библиотеки.

**Хәбибрахман җире**

1910 елларда Гата хәзрәт Хәбибрахман шәкертен Карманга муллалыкка җибәрә. Ул вакытта Хәбибрахман Зәкия исемле кызга өйләнгән була. Карманда зур йортта тора һәм мулла булып эшли.

Яңа гына агач төпләп, барлыкка килгән Карман авылында Хәбибрахманга да җир бирелә. Ул да җирен төпләп басу җиренә әйләндерә. Хәбибрахман шунда гомер итә,үлә һәм Карман зиратына күмелә. Сугыштан соң Нурбаков Газихан белән Яхин Мөнир җирләрне карап йөриләр. Хәбибрахман җиренә килеп җитәләр, карасалар, – җирне әйләнеп, озын чикмән кигән, озын буйлы кеше карап йөри. Бу кеше Хабибрахман була.

-Мөнир, син күрәсеңме? – ди Газихан.

-Күрәм,- ди Мөнир.

Ни гаҗәп, Хабибрахманың үлүенә бу хәлгә кадәр 15 ел вакыт үткән була. Бу хәл әле шулай берничә кабат кабатланган. Шунысы кызык: ул изге, саф күңелле кешеләргә генә күренә.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йорт. 2014 ел.

**Земля Хабибрахмана**

В 1910 годах Гата хазрат отправляет своего ученика Хабибрахмана в деревню Кармановка муллой. К этому времени Хабибрахман был уже женат на Закии. В Кармановке они живут в большом доме, он работает муллой.

Во вновь образованной деревне и Хабибрахману дают землю. Он раскорчевывает выделенный участок и превращает его в пашню. Хабибрахман живет в Кармановке, а когда умирает, его хоронят на кармановском кладбище.

После войны Яхин Мунир и Нурбаков Газихан проверяют поля. Как только подходят к землям Хабибрахмана, видят что поле обходит человек, одетый в длинный зипун . Это оказывается Хабибрахман.

-Мунир, ты видишь?- спрашивает Газихан.

-Вижу, - говорит Мунир.

Что интересно, со дня смерти Хабибрахмана к тому времени прошло уже 15 лет. Такое повторялось еще несколько раз. Примечательно, что Хабибрахмана видели только чистые, добрые люди.

Масагутова Гульзихан Газихановна. д.Султанай, ул.Ленина, д.42. 2014 год.

**Ленинград фаҗигасы**

Бөек Ватан сугышы чорында Ленинград блокадасынан бик күп семья Султанай авылына китерелә. Алар зур бай йортына (2 катлы, 6 бүлмәле элекке правление йорты) урнаштырылалар. Алар колхоз бакчага җиләк-җимеш утырталар. Алар арасында укытучылар да була. Авыл балалары белән дуслаша. Шуннан бер семьяның баласы үлә. Авыл мулласы рус баласын зиратка керетми, Башап-Түз авылы һәм Султанай арадагы буш урынга күмелә. Баланың әнисе сугыштан соң 90елларда кабергә читән куйдыра.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Солтанай, Ленин урамы, 42нче йорт. 2014 ел.

## Трагедия ленинградцев

Во время Великой Отечественной войны семьи многих ленинградских блокадников приехали в Султанай. Их поселили в большой байский дом ( двухтажный с шестью комнатами, бывшее правление колхоза). В колхозном огороде они сажали овощи. Среди них были и учителя. Сельчане подружились с их детьми. В одной из семей умер ребенок. Сельский мулла не разрешил хоронить русского ребенка на сельском кладбище, ребенка похоронили на пустыре между деревнями Султанай и Усть Ашап. В 90-х годах мать ребенка огородила могилку.

Масагутова Гульзихан Газихановна. Д.Султанай, ул.Ленина, д.42. 2014 год

## Онытылган каберләр

Солтанай авылының Суримов Шәрифҗан бакчасының, капкадан кергәч тә абзар якта сул якта калкулыкта граждан сугышы чорында дүртәү акларның солдаты күмелгән, кемнең газиз улларыдыр, билгесез. Бу җир культура һәйкәле исемлегенә кергән, ләкин ул берничек тә билгеләнмәгән. Ул җир сөрелми, ләкин каберлек дип беләбез. Инде хәзер ул йортта торган хуҗалар үлеп бетте. Мондый җирләр онытылмасын иде, ул бит тарих.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Солтанай, Ленин урамы, 42нче йорт. 2014 ел.

## Забытые захоронения

В деревне Султанай в огороде Суримова Шарифзяна за воротами возле овина слева на возвышении во время гражданской войны похоронены четыре белогвардейских солдата. Чьи они сыновья, не известно. Это место вошло в список культурных памятников, но оно никак не отмечено. Это место не пашется, так как мы знаем, что там могила. На сегодняшний день хозяева этого дома уже умерли. Хотелось бы, чтобы такие места не забывались. Ведь это история.

Масагутова Гульзихан Газихановна. Д.Султанай, ул.Ленина, д.42. 2014 год.

С О Д Е Р Ж А Н И Е:

Борчак басу
Гороховое поле
Ракы чишмәсе
Водочный родник
“Мәгәтебәр күле”
Озеро Магатебара
“Майбәдәр күл эч”
Местечко Майбадар
Карман авылы

Кармановка

Мөәзин риваяте

Легеда о муэдзине
Мостовая
Карабай чишмәсе
Черный родник
Шакиров буамнары
Запруды Шакирова
Аракы чишмәсе
Водочный родник
Ибрай чишмәсе
Родник Ибрая
Сөт чишмәсе
Молочный родник
Нуриш басуы
Поле Нуриш
«Паранина яма»
«Семселяк»
«Каратаевка»
«Седловая гора»
«Березовый ключ»
Тауавыл
Усть-Тунтор
Хәбибрахман мөәзин бәете
Баит о муэдзине Хабибрахмане
Школьное привидение
Хәбибрахман җире
Земля Хабибрахмана
Ленинград фаҗигасы
Трагедия ленинградцев
Онытылган каберләр
Забытые захоронения

Составила и перевела зав. отделом обслуживания центральной библиотеки Л.Х.Шакирзянова. 2015 год.